ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21 февраль, 2020 ел **№37/6**

Шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2016 елның 9 ноябрендәге 11/6 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2016 елның 9 ноябрендәге 11/6 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2016 елның 15 декабрендәге 13/7, 2017 елның 15 декабрендәге 21/7, 2018 елның 21 февралендәге 23/9, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/6, 2019 елның 7 октябрендәге 33/6 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 30, 31 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 30. | Коммуналь хезмәтләр күрсәтү | 3.1.1 | 0,11 |
| 31. | Коммуналь хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүче оешмаларның административ биналары | 3.1.2 | 1,04 |

2) 10 пунктны көчен югалткан дип санарга.

2. Карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, Карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасының гамәлгә керү вакыты – 2021 елның 1 гыйнвары.

3.Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ